СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

**27.09.2017** пос. Октябрьский **28-126**

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Октябрьский авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, 1 п., Октябрьский авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Октябрьский авыл җирлеге Советының «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 27-123 номерлы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Октябрьский авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 19 сентябрендәге 13 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Октябрьский авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2018 елда сез Октябрьский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юлларга ризамы:

- Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларында вак таш белән каплап җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары

Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов